**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ МОРДОВСКО-
АФОНЬКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423103, Мордовское Афонькино село, Цаплина ул.,
19 дом

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**МОРДВА АФОНЬКЭСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423103, Мордва Афонькэсе авылы, Цаплин урамы,
19нче йорт

тел. (84396) 3-48-29, факс: (84396) 3-48-49, email: Mord.Cmn2@tatar.ru

№37 23.09.2021 ел

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 сентябрендәге 125 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 сентябрендәге 125 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына (2021елның 22 мартындагы 20 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә: «муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Мордва Афонькәсе авыл җирлеге башлыгы, Совет рәисе — А.И.Митяев